بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ، الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ
وَالصَّلاةُ وَالسَّلامُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِهِ وَأَصْحَابِهِ الطَّيِّبِينَ الطَّاهِرِينَ

Аллаһы Тәгалә Исеме белән бөтен яхшы эшләрне башлыйм, Ул – Аллаһ бөтен колларына ошбу дөньяда рәхмәтләр бирә. Әмма Ахирәттә – фәкъать мөэмин-мөселманнарга гына рәхмәтләр бирә.

Җәбер – золым кешеләрнең дөнья ләззәтләрен үлем белән бетергән һәм мөселманнарны явызлардан коткаручы Аллаһыга бөтен мактау-шөкерләр булсын!

Аллаһы Тәгаләнең иң сөекле Пәйгамбәре һәм колы Му<u>х</u>әммәдкә – <u>С</u>аләүәт!
Йә, Рабби, Му<u>х</u>әммәд Пәйгамбәребезнең дәрәҗәсен тагын да күтәр!
Йә, Аллаһ, безгә файдалы белем биреп, гөнаһлардан сакланырга вә фарызларны үтәргә көч-күвәт нәсыйб ит!
Тәкъва колларыңнан булырга мөәссәр әйлә!
Аллаһы Тәгалә Корәндә әйтте:
(وَالَّذِينَ جَاؤُوا مِن بَعْدِهِمْ يَقُولُونَ رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَ لِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالإِيمَانِ وَلا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلاًّ لِّلَّذِينَ ءامَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ {10})
Әль-<u>Х</u>әшр Сүрәсенең 10-че Аяте.
Мәгънәсе: бер кавым мөселманнардан соң яшәгән башка кавым мөселманнар әйтәләр: “Йә, Рабби, безнең гөнаһларыбызны ярлыка һәм бездән элек яшәгән мөселманнарның гөнаһларын гафу ит, вә мөселманнарга карата йөрәкләребезгә мөхәббәт бир, яман хисләрдән сакла, Йә, Рабби, Син рәхмәт бирүче, мөселманнар өчен хас мәрхәмәт кылучы”.

Пәйгамбәребез Му<u>х</u>әммәд, ‘аляйһиссәләм, әйтте:
[يٰسۤ قَلْبُ الْقُرْءَانِ لاَ يَقْرَؤُهَا رَجُلٌ يُرِيدُ اللهَ وَ الدَارَ الآخِرَةِ إِلاَّ غُفِرَ لَهُ، وَ اقْرَءُوهَا عَلَى مَوْتَاكُم] رَوَاهُ الإِمَامُ أَحْمَدُ فِي مُسْنَدِهِ.
Ошбу Хәди<u>с</u>не Имам Әхмәд “Муснәд” -ендә риваять итте.
Мәгънәсе: “Йәсин – Коръәннең йөрәге, кем ошбу Сүрәне Аллаһ ризалыгы өчен, ахирәтне макъсат итеп укыса – гөнаһлары гафу ителер. Мәетләрегезгә Йәсин Сүрәсен укыгыз”.
Динебез – Ислам: бердән бер хак Дин. Ислам диненнән башка дөрес дин юк! Һәм динебездә иң мөһим булган белем – Аллаһы Тәгалә турында һәм Пәйгамбәребез Му<u>х</u>әммәд Мостафа турында мәгълүмәтләр. Шушы гыйлемгә “гыйлм әт-тәү<u>х</u>ид” диелә.
Мөселманнарга белергә кирәк булган нәрсәләрдән:
Аллаһы Тәгалә һич бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел.
Ул барча кимчелекләрдән пакь вә өстен.
Һичбер урында түгел, һичбер тарафта түгел. Аның өсте-асты, уңы-сулы, алды-арты юк. Ул барча мәхлүкатьләргә урын яралтты, Үзе исә урынсыз бардыр. Ул һичбер нәрсәгә охшамаган.
Аллаһ – Бер, Аның тиңдәше юк, Аның охшашы юк, Аның уртагы юк (шәриге юк). Ул – Бер, бүленмәс, чөнки җисем түгел, тәнсез, гәүдәсез. Аның әгъзалары, кысымнары юк.

Аллаһ бөтен нәрсәне күрүче – әмма күз белән түгел! Күрүе яктылыкка мохтаҗ түгел, чөнки Аллаһ Үзе яктылыкны да, караңгылыкны да яралтты – юктан бар итте.
Ул барча тавышларны ишетүче – әмма колак белән түгел!
Аның Кодрәте һәр нәрсәгә җитүче. Әмма кул вә көч белән түгел! Ул арымый, талмый һәм ял итми.
Аллаһның барлыгы әүвәлсез вә ахырсыз.
Ул теләгән нәрсә була, теләмәсә – һичбер нәрсә булмас. Аңа беркем дә әмер бирәлми, вә тыялмый.
Аллаһ һәрбер нәрсәне белүче, әмма өйрәнү белән түгел! Аллаһның белеме артмас, кимемәс һәм үзгәрмәс. Аллаһ һичбер нәрсәне онытмый!
Аллаһ – тередер, әмма тере булганы рухсыз, җансыз, кансыз, йөрәксез, гәүдәсез.
Аллаһ сөйли, әмма тел-теш белән түгел, авыз-үпкә кулланмастан, гарәп-төрки телләрдә түгел. Сөйләүе хәреф-сүз түгел, аваз түгел, җөмлә түгел. Сөйләүе әүвәлсез, ахырсыз һәм туктаусыз.
Кагыйдә шундый: нинди булса фикер белән төшенгән нәрсә – ул яратылмыш, Аллаһ аңа охшамас!
Әмма Пәйгамбәребез Му<u>х</u>әммәд – Абдуллаһның улы, бабасы – Абдулмутталиб, бабасының этисе – Һәшим, бабасының бабасы – Абдумәнәф. Гарәпләрнең “Кораеш” дигән кабиләдән. Туды Мәккә шәһәрендә, 40 яшендә вәхий иңде Үзенә, 53 яшендә Мәдинә шәһәренә Һиҗрәт кылды, күчте (руми тәкъвим буенча 622-че йылга якын).
Һәм 63 яшендә Мәдинә шәһәрендә вафат итте.
Без – мөселманнар барча Пәйгамбәрләрне таныйбыз, Аларга эшанабыз. Беренчесе – Адәм ‘аляйһиссәләм, соңгысы – Му<u>х</u>әммәд <u>с</u>олляллаһу ‘аляйһи үә сәлләм. Дөньяга килгән Пәйгамбәрләрнең саны – 124 мең. Барысы да – Ислам Дине белән килделәр, барчасы да мөселман.

لا إلـٰـهَ إلاّ الله

Пәйгамбәрләр бөтенесе дә:

“Ля́ иля́һә илляллб́һу” – “Аллаһтан башка Тәңре юк”, – диеп әйтеп йөрегәннәр.
Бөтен Пәйгамбәрләр гөнаһсызлар! Алар бөтенесе дә мөселманнар!
Һич бересе дә Ислам диненнән башка динне өйрәтмәделәр. Һич бересе дә ай, кояш, йолдыз, ут, потларга табынмаганнар. Тугач ук мөселман булып, үлгәндә дә мөселман булып вафат иткәннәр!

Әмма зур гөнаһлар – зина кылу, урлау кебек, бу эшләргә бер нинди Пәйгамбәр якынлашмады.
Алардан beресе дә Пәйгамбәрлек дәрәҗәсен төшерүче эш кылмаганнар: зур гөнаһ кылу түгел, кечкенә гөнаһларны да эшләмәделәр. Мәсәлән: кешене алдау, рәнҗетү, кимсетү, йәзем бөртеге кадәр нәрсәне урлау.
Шулай ук Пәйгамбәрләр арасында һич берәсе дә җирәндерүче чир-сырхау белән чирләмәде. Чөнки шушы мәсъәләдә йыш кына Әййюб Пәйгамбәргә яла ягып әйтәләр: “Ул шундый чир белән чирләгән, Аңардан бөтен халык җирәнеп киткәннәр” – дип, үзләрен гөнаһ-көферлеккә батыралар. Кайсылары тагын да – “тәне черегән” – диләр. Бу да һич дөрес түгел. Шушы кешеләр Әййюб Пәйгамбәрнең чын сабырлыгын күрсәтергә тырышып, Пәйгамбәрләргә лаек булмаган сыйфатлар кушалар. Андый фикер – Ислам динебезгә каршы!
Дөреслектә, Әййюб ‘аляйһиссәләм, бер авыр чир белән чирләгән, ләкин Аның тәне черемәгән, ите гәүдәсеннән айырылып төшмәгән, әмма йөрергә авыр булган, балалары үлгән, малы юкка чыккан. Мәгәр Әййюб Пәйгамбәр сабыр иткән. Аллаһы Тәгалә үзенә шифа биреп, тагын күп бала вә маллар нәсыйп иткән.
Шуңа күрә Пәйгамбәрләр Аллаһның диненә чакыручылар булып дөньяга җибәрелгәннәр, Аларның төп максатлары – кешеләрне берләштереп Үзләренә оеп, артларыннан барып, Аллаһыга ышанырга вә табынырга өйрәткәннәр. Әгәр Аларда кешене куркырлык нәрсә булса иде – кешеләрне Дингә өндәү вазыйфәсе өстләрендә булмас иде, һәм Пәйгамбәр булмаслар иде.
Пәйгамбәрләрнең барысы да бик матур-гүзәлләр: битләре дә, тавышлары да, тәннәре дә, әхлаклары да, сүзләре дә – һәр нәрсәләре йәмле вә чорайлы. Муса Пәйгамбәрнең теле сакау булмаган – Ул сөйләгәндә сүз-хәрефләрне дөрес әйтер иде.
Юсүф Пәйгамбәр бир нинди хатынга шәһүәт күзе белән карамады, чөнки андый бакыш (карау) Пәйгамбәрләргә лаек түгел. Зөләйха – бер вәзирнең хатыны Юсүф Пәйгамбәрне зина кыларга өндәде, тырышты һәм теләп торды, әмма Юсүф Пәйгамбәр ул хатынны этәргә уйлап торганда, Аллаһы Тәгалә әмер бирде этәмәскә – әйләнеп, борылып яныннан китәргә. Юсүф Пәйгамбәр шул турында төшенгәнен вәһһәбийләр (хак юлдан тайпылган агым, Исламнан чыккан фирка) игълан итеп Пәйгамбәрләргә яла ягалар, ифтиралар атып, Пәйгамбәрләрнең дәрәҗәләрен төшерергә тырышып торалар.

Алар Ибраһим Пәйгамбәрне масхәрәләп: “ай-кояш һәм йолдызларга табынып Аллаһне эзли торган”, – диеп ялган әйтәләр. Бу сүзләрне һичбер Пәйгамбәргә әйтергә булмый, ярамый.

Бу ялганчы ваһһабийләр безнең Пәйгамбәребезне дә: “вәхий иңгәче адашып йөрегән, хакны белмәгән”, дип – Пәйгамбәрлек килгәннән элек “кяфер” булганын иглан итәләр. Безнең иң бөек Пәйгамбәребезне хурлыйлар!

Шушы вәһһәбийләр Аллаһтан курыкмыйлар, Пәйгамбәребездән оялмыйлар!

Без борынгы заманнардан бирле мөселман мәетләребезгә Коръән укытабыз, дога кылабыз, Пәйгамбәребезне хөрмәтләп мәүлид укытабыз.

Бу вәһһәбийләр әйтүләре буенча: “кеше үлгәч, аңа башкача бер ни дә файда бирми”, – дияләр.

Коръән вә мәүлид укытуны тыялар, “ярамый”, – диләр.

Шундый мәҗелесләргә хәзеләнгән хәлал итләрне – дуңгыз ите кебек диләр. Мөселманнарга бетү йөретергә ярамый, диләр. Алар Динне бозырга эш алып баралар.

Андый фиркалардан йырак булыгыз. Сак булыгыз!

Безнең мөселман гореф-гадәтләрне бозучыларны тыңламагыз, алар әткән сүзләрне акылыгызга кертмәгез!

***Коръән уку шартлары***

Ислам, Коръән укучы мөселман булырга тиеш.

Коръәнне дөрес укырга тиешле.

Коръәнне хөрмәтләп уку.

Коръәнне лаек җиргә куеп уку һәм саклау, Аны аяк алдына куярга ярамый, аяк белән бер биеклектә булса Аңа таба аяк сузарга ярамый.

Өйрәнеп уку (китаптан гына өйрәнү дөрес түгел).

Туктарга кирәк булган җирдә туктау, үзып китә торган җирдә – үтәргә. Чөнки Коръән уку дөрес булсын өчен Аның мәгънәсе бозылмаслык итеп уку тиешле.

Кем Коръәнне чын күңел белән дөрес укыса – аңа һәр хәрефе өчен ун Сәвап бирелә. Шулай ук чын күңел белән тыңласа – һәр хәрефе өчен бер Сәвап бирелә.

Коръән китабын тотып укыса Тәһәрәтле булу тиешле.

***Коръән укудан сәвап алыр өчен ни кирәк:***

Фарызларны үтәгән кеше булырга тиеш.

Диндә зарурий белеме булырга тиеш.

Ихләс күңел белән уку. Кем Коръәнне кеше мактасын өчен укыса, я дә озын-озак укып – кешеләр җәлләсеннәр, диеп укыса, сәвап түгел – гөнаһ алыр.

***Коръән укуда фәзыйләтләре***

Уку алдыннан сивак куллану (сивак, мисвак – теш чистарта торган агач тамыры).

Коръән укыганда Кыйбла тарафына юнәлеп тезләнеп утырырга.

Тә‘ауүз – “ә‘ҿу́зү билля́һи минәш-шәйто́нир-роджи́м”не Коръән уку алдыннан әйтү.

Бәсмәләһ – “Бисмилля́һир-рохмә́нир-рохы́м”не Коръән Сүрәләренең башында әйтү, әмма Тәүбә Сүрәсе Бәсмәләһдән башланмый!

Коръән укудан хәсыйл булган Сәвабларны иң башта Пәйгамбәребезгә багышлап, бөтен Пәйгамбәрләргә багышлау. Аннан соң барча мөэмин-мөселман мәетләребезнең рухларына багышларга.

Коръәнне каты тавыш белән кычкырып укымаска.

Коръәнне яхшы матур көй белән уку яхшырак, әмма көйләгәндә хата-үзгәртүлүр ясарга ярамый.

Коръәнне Тәҗвид һәм Тәртил белән уку яхшы.

Коръәнне үз вакытында укырга – башка кешеләрне рәнҗетмәскә (йоклаган кеше янында йокысын бозып, я дә эшләгән вакытта эшеннән мәҗбур хәлдә туктатып).

Коръән укып Дога кылганда искә алырга кирәк: хәләл ашамлык ашаган кешенең догасы кабул булуның ихтималы күберәк. Элек безнең изге бабайлар бик чирле-сырхау кеше янына барып Коръән-дога укып, шифа теләп торганда ук, шул чирле кеше күз алдында терелеп китәр иде. Бу ни өчен шулай булган икәнен аңлатып була: алар хәләл ризык ашаганнар, фарызларны үтәгәннәр, казага калдырмаганнар, гөнаһлардан сакланганнар. Шуңа күрә догалары кабул булган. Безгә дә шундый үрнәкләрне өйрәнеп, үзебезгә ошбу юлда булырга тиешбез.

---

# КАЙСЫБЕР ДОГАЛАР

## 1. Мәҗелескә килеп утыргач

(اللَّهُمَّ رَبِّ أَنزِلْنِي مُنزَلاً مُّبَارَكًا وَأَنتَ خَيْرُ الْمُنزِلِينَ)

“Алла́һуммә Робби әңзилни́ мүңзәлән мүбә́рокән
уа Әңтә хъойрул-муңзили́н”.

Әл-Муминүн Сүресенең 29 Аятеннән.
Аллаһы Тәгаләгә барча мактау-шөкерләр булсын!
Мухәммәд Пәйгамбәребезгә – Саләүәт.
Йә, Рабби, ошбу килүебезне хәерле кыл, бу өйгә һәм өй хуҗаларына тынычлык, бәхет-сәгадәть, саулык-сәләмәтлек, иман байлыгын вә бәрәкәт бир!
Догаларыбызны кабул ит! Мөэмин мәетләребезгә рәхмәт кыл! Шушы мәҗелесне мөбәрәк кыл!

## 2. Садака догасы

(اللَّهُمَّ □حْفَظْ صَاحِبَ هَذِهِ الصَّدَقَاتِ مِنَ الْبَلاءِ وَ الأمْرَاضِ
وَ □غْفِرْ ذُنُوبَنَا وَ □رْحَمْ مَوْتَانَا وَ □شْفِ مَرْضَانَا
وَ تَوَفَّنَا وَ أَنْتَ رَاضٍ عَنَّا ، يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِين)

“Алла́һуммә-хфәзъ со́хибә һә́зиһис-содәкъо́т минәль-бәля́-и үәль-әмро́дъ, үәгъфирь зүнү́бәнә́ үәрхәм мәүтә́нә́ үәшфи мәрдо́нә́, үә тәүәффәнә́ үә Әңтә ро́дын ‘ɛаннә́, йә́ әрхәмәр-ро́хыми́н”.
Йә, Рабби, бирелгән садакаларны кабул кыл! Һәм садака бирүчеләрне бәла-казалардан, авыру-сырхаулардан сакла! Гөнаһларны гафу ит, мөселман мәетләребезгә рәхмәт кыл! Касталарга – шифа бир! Безне иманыбыздан айырма! Мөэмин-мөселман булып Ахирәткә күчәргә нәсыйп кыл! Догаларыбызны кабул ит! Күп изгелек вә сәвап нәсыйп ит!

## 3. Аш ашаганнан соң укыла торган Дога

(□لحَمْدُ ِللهِ □لَّذِي أَطْعَمَنَا وَ سَقَانَا وَ جَعَلَنَا مُسْلِمِينَ)

“Әл-хәмдү лилля́һил-лязи әт‘ɛамәнә́ үә сәкъо́нә́ үә җә‘ɛалянә́
мүслими́н”

Аллаһы Тәгаләгә барча мактау-шөкерләр булсын! Ул шушы ризыкларны бирде, Ул гына ризык бирүче, Ул безне туйдыручы. Аллаһ безне мөселманнар кылган өчен шөкрана итәбез бер Раббыбызга! Шушы мәҗелесне җыйганнарга, аш пешерүчеләргә, ярдәмчеләргә Аллаһ саулык бирсен! Кул-аякларыгыз сызлаусыз булсын! Аллаһ бу өйгә һәр заман киң хәләл ризыклар нәсыйп итсен! Көтмәгән җирдән шатландырсын! Хәерле Догаларыбызны кабул кылып иң яхшысыны бирсен!

## 4. Кунакта авыз ачкач хуҗаларга укырга

(أَفْطَرَ عِنْدَكُمُ □لصَّائِمُونَ وَ أَكَلَ طَعَامَكُمُ □ٱلأَبْرَارُ
وَ صَلَّتْ عَلَيْكُمُ □لْمَلآئِكَةُ)

“Әфторо ‘ƹыңдәкүмуссóимýн, үә әкәлә то‘ƹáмүкумуль-әбрóр, үә соллят ‘ƹаляйкүмүль-мәля́-икяһ”.

Сез тәкъдим иткән ашларыгызны ураза тотучылар ашап авыз ачтылар, һәм шулай йышырак булып сезгә Аллаһы Тәгалә күп киң ризыклар нәсыйп итсен! Сезнең ашларыгызны изге кешеләр ашап сезгә һәр вакыт Догалар укысыннар! Сезгә Фәрештәләр Догаларын бирсеннәр! Аллаһы Тәгалә сезгә һидәятен биреп, хәерле эшләрегезне кабул итеп, гөнаһларны гафу итсен!

Шуңа охшаган шатлыклы мәҗелесләрне йышырак үткәрергә Аллаһы Тәгалә сезгә ярдәм бирсен. Нинди изге теләкләрегез бар – сезгә тагын хәерлесе нәсыйп булсын! Әмин.

~

Тәлкъыйн Догасы
(Мөселман мәетен күмгәч укыла,
үле мөселман булмаса – бернинди Дога укырга ярамый!)

πيَا عَبْدَ اللهِ ابْنَ أَمَةِ اللهِ ، يَا عَبْدَ اللهِ ابْنَ أَمَةِ اللهِ ،
يَا عَبْدَ اللهِ ابْنَ أَمَةِ اللهِ ، أُذْكُرْ الْعَهْدَ الَّذِي خَرَجْتَ عَلَيْهِ مِنَ الدُّنْيَا: شَهَادَةِ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ
وَ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ ، وَ أَنَّ الْجَنَّةَ حَقٌّ،
وَ أَنَّ النَّارَ حَقٌّ، وَأَنَّ الْبَعْثَ حَقٌّ ، وَ أَنَّ السَّاعَةَ آتِيَةٌ
لاَ رَيْبَ فِيهَا، وَ أَنَّ اللهَ يَبْعَثُ مَن فِي الْقُبُورِ،
وَ أَنَّكَ رَضِيتَ بِاللهِ رَبًّا ، وَ بِالْإِسلاَمِ دِينًا ، وَ بِمُحَمَّدٍ ε نَبِيًّا، وَ بِالْقُرْءَانِ إِمَامًا ، وَ بِالْكَعْبَةِ قِبْلَةً ، وَ بِالْمُؤْمِنِينَ إِخْوَانًاι

Тәлкыйн Догасының транскрипциясы

“Йә, ‘ɛабдәллáһ ибн әмәтилля́һ, йә, ‘ɛабдәллáһ ибн әмәтилля́һ, йә, ‘ɛабдәллáһ ибн әмәтилля́һ, үзкүриль-‘ɛаһдәллязи́ хъораджтә ‘ɛаляйһи минәд-дунья́: шәһәдәти әлля́ иля́һә илляЛлáһү, үәхдәһý ля́ шәри́кя ляһү үә әннә Мухәммәдән ‘ɛабдүһý үә Расýлюһý, үә әннәль-Джәннәтә – хәкъкъун, үә әннә-ннәро хәкъкъун, үә әннәль-бә‘ɛсә хәкъкъун, үә әннәс-сә́‘ɛатә ә́тиятүн ля́ ройбә фи́һә́, үә әннәЛлáһә яб‘ɛасү мәң филь-къубýр, үә әннәкя родый́тә биЛля́һи Роббән, үә биль-Исля́ми Ди́нән, үә би-Мухәммәдин солляллáһү ‘ɛаляйһи үә сәллямә нәбиййян, үә биль-Къур’ә́ни имә́мән, үә биль-Кя‘ɛбәти къыблятән, үә биль-мү’мини́нә ихъүә́нән”.

**Иманыбыз – иң зур байлык!**

Кадерле укучылар! Ислам Динебез – иң зур байлык!

Ислам Динебез – иң зур бәхет! Аны хөрмәт итеп сакларга кирәк. Чөнки Исламнан чыгып кәфер булган кемсәнең гөмер буе тырышып казанган сәваплар юкка чыга, бөтен изгелекләр югала.

Шушындый кеше – бөтен гөмерен гөнаһ эшләүдә генә үткәргән дәен була. Һич яхшылыгы калмый!

Шуңа күрә: без иманның нигезләрен өйрәнеп, иманны боза торган нәрсәләрне дә белергә тиешбез. Иманны көфердән айыра торган мәгълүмәтләр бик мөһим, чөнки Ислам галимнәрнең олыглары әйттеләр: кем гөнаһларны нәрсә икәнен белмәсә – аңа батырга ихтимал зур. Без шул 3 төрле көферлекне кылмас өчен аларны өрәнеп китиек.

**КӨФЕРНЕҢ ӨЧ ТӨРЛЕЛӘРЕ**

Көфер – Ислам диненнән чыгу. Динсез калу. Кәфер булу.

Аллаһы Тәгалә барыбызны да көфердән сакла!

Имам Әгъзам Әбу Хәнифә һәм башка галимнәр әйтүләре буенча көферлек 3 кысымга бүленә: ышануда, гамәлдә һәм сүзләрдә.
*Ышануда* (игътикадтә иман итәргә ярамаган).
*Гамәлдә* (эшләргә ярамаган).
*Сүзләрдә* (тел белән әйтергә ярамаган).
Кардәшлеребез! Мөэмин-мөселман кеше шуны белергә тиеш: имансызлык – иң зур гөнаһ, үлем алдыннан шул гөнаһыннан Исламга кайтып тәүбә итмәгән кешене Аллаһы Тәгалә гафу итми. Андый кеше – кәфер, Җәннәткә кермәс һәм Җәннәтнең исен дә сизмәс! Шуңа күрә татар халкында иң хурлыклы сүз "имансыз" – дию. Бу гөнаһ кешенен бөтен яхшы-изге гамәлләренең сәвабын юкка чыгара.

*

***өч төрле көфердән сак булыгыз!***

**1. Күңелдә көфер.**

Аның урыны – йөрәк. Мәсәлән, Аллаһы Тәгаләне нәрсәгәдер тиңләү, Аны яктылык яисә рух диеп уйлау, Ул күкләрдә-җирләрдә булып тора диеп уйлау, Ул Гарше өстендә утыручы җисем диеп күз алдына китерү.
Имам Әхмәд ибн Хәнбәл (һиҗри 174 елда туган) һәм имам Сәубән ибн Ибраһим Зүннүн Әл-Мысрий (һиҗри 245 йылда үлгән) әйткәннәр: "Аллаһы Тәгаләне күз алдына китереп булмый, Ул бернигә дә охшамаган".

**2. Гамәлдә көфер.**

Мәсәлән, белә торып Коръән Кәримне, Яисә Дини язуны вә Аллаһы Тәгаләнең Исеме язылган кягазьне чүплеккә ташлау, пычырату (нинди телдә язылган булса да).

**3. Тел (сүз) имансызлыгы.**

Шулдыр ки, кем нинди булса Пәйгамбәрне, Фәрештәне, Коръән Кәримне, Кәгъбәне, Ислам Динен хурласа, сүгсә, кимсетсә.
Әйтергә ярамаган мисаллардан: "Алла бабай", – дияләр.
Кешеләр арасында ишетелгән, дингә каршы булган сүзләрдән: "Алланың сакалы ак", – диеп, кяфер булалар.
Кайсыберләр Аллаһыга тән, кул, аяк, баш, тел, бит кебек әгъзалар кушалар.
Тәкъдирне инкәр итеп, яшь кеше үлсә: "Үз үлеме белән үлмәгән", – диеп, ялгышалар.

Бик якын туган кеше үлсә, кайсы бер кешеләр Аллаһка: “нигә аның җанын алдың, бу бит гаделсез”, – диеп, Диннән чыгалар.
Шуңа охшаган әшәке сүзләр әйтүдән бик ерак булыгыз!

%

**Белемнең өстенлеге һәм ниятләрнең чынлыгы.**

Абу Кәбш Гомәр ибн Сәгадә Әл-Әнмәрий, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аңа яусын, Пәйгамбәребезнең шундый сүзләрен ишеткән: “Мин сөйлим, сез хәтерегездә калдырыгыз”. Дөреслектә тормышта 4 төрле кеше була:
1. Кемгә Аллаһы Тәгалә байлык вә белем биргән. Ул Аллаһы Тәгаләдән курка, Аның Әмерләрен үти, туганнары белән бергә була һәм булыша, Аллаһы Тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен бурычлы булганын белә, онытмый, дөрес куллана. Ул иң яхшы хәлдәгеләрдән.
2. Кемгә Аллаһы Тәгалә белем биргән, ләкин байлык бирмәгән. Ул дөрес ниятле: “Әгәр дә байлыгым булса иде, теге беренче зикерләнгән кеше кебек яшәр идем”. Якшы нияте өчен аңа да шулай ук сәвап.
3. Кемгә Аллаһы Тәгалә байлык биргән, ләкин белем бирмәгән. Ул кемсә байлыгын белмича, файдасызга куллана, туганнары белән аралашмый, булган байлыгы өчен Аллаһы Тәгаләгә бурычлы икәнен аңламый. Бу кол иң мәсхәрәле хәлдә.
4. Кемгә Аллаһы Тәгалә ни байлык, ни белем бирмәгән – ул кемсә әйтә: “Әгәрдә минем байлыгым булса иде, мин дә теге алдагы (өченче) кеше кебек яшәр идем”. Бозык нияте өчен ул да шундый ук хурлыклы хәлдә.
Бу сүзләрне Әт-Тирмизий тапшырды вә дөреслеген раслады.
Әйтемләрнең бересендә Динебезгә һич туры килмәгән сүзләр бар, алар: “белмәгәннең беләге авыртмый”. Наданлык – кимчелек. Бер кайчан да надан кеше өстен булмаган. Гылем – нур. Наданлык гөнаһларны эшләгән кешегә гозер булса иде, гөнаһ кыйлучы: “мин белмәдем бит”, – диеп, сөәл-сораулардан вә газәптән котылса иде, наданлык белемнән өстен һәм яхшырак булыр иде. Әмма хакыйкат анлай түгел! Гыйлем наданлыктан өстен. Гыйлем булган кеше гамәл кылса – бәрәкәтле булыр!

“Йә, Рабби, безгә ошбу дөньяда да ахирәттә дә изгелек бир һәм
җәһәннәм утыннан коткар”.
фәфәфәфәфә

(رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالإِيمَانِ وَلا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلاًّ لِّلَّذِينَ ءامَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَؤُوفٌ
رَّحِيمٌ)
“Роббәнәг̲ъфирь ляна́ үә ли ихъүа́нинәлляз̲инә сәбәк̲ъу́на́
бил-и́ма́н, үә ля́ тәдҗаль фи́ к̲ъулю́бина́ гъылляль-лилляз̲и́нә а́мәну́,
Роббәна́ иннәкя рау́фур-рох̲ы́м”.
Мәгънәсе: “Йә, Рабби, безнең гөнаһларыбызны ярлыка һәм бездән элек яшәгән мөселманнарның гөнаһларын гафу ит, вә мөселманнарга карата йөрәкләребезгә мөхәббәт бир, яман хисләрдән сакла. Йә, Рабби, Син рәхмәт бирүче, мөселманнар өчен хас мөрхәмәт кылучы”.
фәфәфәфәфә

(رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَتَوَفَّنَا مُسْلِمِينَ)
“Роббәна́ әфригъ ‘ع аляйна́ с̳обран үә тәүәффәна́ муслими́н”.
Мәгънәсе: “Йә, Рабби, безгә сабырлык-чыдамлык бир һәм мөселман булып шушы дөньядан китәргә нәсыйп ит!”
фәфәфәфәфә
(رَبَّنَا ءَاتِنَا مِن لَّدُنْكَ رَحْمَةً وَهَيِّئْ لَنَا مِنْ أَمْرِنَا رَشَدًا)
“Роббәна́ а́тина́ миллядүңкя рох̲маһ, үә һәййиъ’ ляна́ мин әмрина́
рошәда́”.
*Мәгънәсе: “Йә, Рабби, безгә рәхмәт вә мәгъфирәт бир һәм яхшы эшләребезне уңайлы ит, иршәд бир, тугры юл күрсәт”.*
фәфәфәфәфә

(رَبَّنَا اصْرِفْ عَنَّا عَذَابَ جَهَنَّمَ إِنَّ عَذَابَهَا كَانَ غَرَامًا)
“Роббәнәс̳риф ‘ع анна́ ‘ع аз̲а́бә джәһәннәмә, иннә ‘ع аза́бәһа́ кя́нә
гъора́ма́”.
*Мәгънәсе: “Йә, Рабби, безне җәһәннәм утыннан, тәмуг газабыннан коткар, чөнки ул газаб бик авыр һәм каты”.*
фәфәфәфәфә

(رَبَّنَا هَبْ لَنَا مِنْ أَزْوَاجِنَا وَذُرِّيَّاتِنَا قُرَّةَ أَعْيُنٍ وَاجْعَلْنَا لِلْمُتَّقِينَ إِمَامًا)
“Роббәна́ һәбь ляна́ мин әзүа́джина́ үә з̲үррийййәтина́ к̲ъуррата ә‘ع юн, үә-дж‘ع альна́ лиль-мүттәк̲ъы́нә имә́ма́”.

*Мәгънәсе: “Йә, Раббыбыз, безгә хатыннарыбыздан вә гаиләләребездән – шатлык вә җан рәхәтлеген күрергә нәсыйп ит. Һәм безгә тәкъва кешеләрнең имамнары булырга нәсыйп кыл”.*

фəфəфəфəфə

Намазда укыла торган ӘТТӘХ̲ИЙЙЯТ Догасы:

πالتَّحِيَّاتُ ِللهِ وَ الصَّلَوَاتُ وَ الطَّيِّبَاتُ، السَّلاَمُ عَلَيْكَ أَيُّهَا النَّبِيُّ وَ رَحْمَةُ اللهِ وَ بَرَكَاتُهُ،

السَّلاَمُ عَلَيْنَا وَ عَلَى عِبَادِ اللهِ الصَّالِحِينَ،

أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ ι

“Әттәх̲иййя́түү лилля́һи уас̳с̳оля́үә́тү үәт̲т̲ойййбә́т, әссәля́му ‘ع͏аляйкя әййюһән-нәбиййю үә рах̲мәтүлла́һи үә бәрокя́түһү, әссәля́му ‘ع͏аляйнә́ үә ‘ع͏аля́ ‘ع͏ыбә́дилля́һис̳-с̳о́лих̲ы́н, әшһәдү әлля́ иля́һә иллялла́һ, үә әшһәдү әннә Мух̲әммәдән ‘ع͏абдүһу́ үә расу́люһү”.

*Мәгънәсе: “Аллаһыга барча мактау, олыглау, намазлар. Сәлам Сиңа, Аллаһның Пәйгамбәре. Аллаһның рахмәте һәм бәрәкәте Сиңа булсын! Сәлам булсын безгә һәм Аллаһның изге колларына!*

*Мин беләм, ышанам һәм таныклык сүз әйтәм ки: Аллаһыдан башка Тәңре юк.*

*Һәм мин беләм, ышанам вә таныклык сүз әйтәм ки: Мух̲әммәд – Аллаһының колы һәм Илчесе (Расүле).*

фəфəфəфəфə

С̳аляүәт Догасы:

πاللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ

وَ عَلَى ءَالِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ‘

اللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ

وَ عَلَى ءَالِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ι

Алла́һуммә с̳алли ‘ع͏аля́ Мух̲әммәд, үә ‘ع͏аля́ ә́ли Мух̲аммад, кяма́ с̳алляйтә ‘ع͏аля́ Ибра́һи́м, үә ‘ع͏аля́ ә́ли Ибра́һи́м, иннәкя х̲әми́дүм-мәджи́д.

Алла́һуммә бә́рик ‘ع͏аля́ Мух̲әммәд, үә ‘ع͏аля́ ә́ли Мух̲аммад, кяма́ бә́рактә ‘ع͏аля́ Ибра́һи́м, үә ‘ع͏аля́ ә́ли Ибра́һи́м, иннәкя х̲әми́дүм-мәджи́д.

+

НАМАЗ КЫЛГАННАН СОҢ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

الْحَمْدُ ِللهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ وَ الصَّلاَتُ وَالسَّلاَمُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِهِ وَصَحْبِهِ وَسَلَّمْ.

اللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنَّا صَلاَتَنَا وَصِيَامَنَا وَقِيَامَنَا وَقِرَاءَتَنَا وَرُكُوعَنَا وَسُجُودَنَا وَقُعُودَنَا وَتَسْبِيحَنَا وَتَهْلِيلَنَا وَتَخَشُعَنَا وَتَضَرُّعَنَا.
اللَّهُمَّ ارْحَمْ مَوْتَانَا وَاشْفِ مَرْضَانَا.
اللَّهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَلآبَائِنَا وَأُمَّهَاتِنَا وَإِخْوَانِنَا وَأَخَوَاتِنَا وَمَشَايِخِنَا وَأَسَاتِذَنَا.
ربَّنَا اغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا وَإِسْرَافَنَا فِي أَمْرِنَا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وانصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ.
رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالإِيمَانِ وَلا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلاًّ لِّلَّذِينَ ءامَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ.
اكْتَسَبَتْ رَبَّنَا لاَ تُؤَاخِذْنَا إِن نَّسِينَا أَوْ أَخْطَأْنَا رَبَّنَا وَلاَ تَحْمِلْ عَلَيْنَا إِصْرًا كَمَا حَمَلْتَهُ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِنَا رَبَّنَا وَلاَ تُحَمِّلْنَا مَا لاَ طَاقَةَ لَنَا بِهِ وَاعْفُ عَنَّا وَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَآ أَنتَ مَوْلاَنَا فَانصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ.
اللَّهُمَّ اهْدِنَا وَاهْدِ بِنَا وَاجْعَلْنَا سَبَبًا لِمَنِ اهْتَدَى
عَلَى نِيَّةِ الْقَبُولِ وَ التَّوْفِيقِ - الْفَاتِحَة.

## ӘЛЬ-ФӘТИХӘ (ӘЛХӘМ) СҮРӘСЕ

سُورَةُ الْفَاتِحَة

(بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ{1} الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ{2} الرَّحْمنِ الرَّحِيمِ{3} مَلِكِ يَوْمِ الدِّينِ{4}
إِيَّاكَ نَعْبُدُ وإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ{5} اهدِنَا الصِّرَاطَ المُستَقِيمَ{6} صِرَاطَ الَّذِينَ أَنعَمتَ عَلَيهِمْ غَيرِ المَغضُوبِ
عَلَيهِمْ وَلاَ الضَّالِّينَ{7}) ءَامِين

“Бисмилляһир-рохмәнир-рохым

1. Әль-хәмдү лилляһи роббиль-‘ә́ләми́н. 2. Әр-рохмә́нир-рохы́м. 3. Мә́лики яумидди́н. 4. Иййя́кя нә‘будү үә иййя́кя нәстә‘ы́н. 5. Иһдинәссыро́толь-мустәкъы́м. 7. Сыро́толлязи́нә ән‘амтә ‘аляйһим. Гойриль-мәгъду́би ‘аляйһим үә ляддо́лли́н”. Әми́н.

## ӘЛИФ ЛЯМ-МИМ

(Әл-Бәкара Сүрәсенең 5 Аяте)

سورة البقرة

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

(الٓمٓ {1} ذَلِكَ الْكِتَابُ لاَ رَيْبَ فِيهِ ، هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ {2} الَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِالْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ الصَّلَوٰةَ وَمِمَّا
رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ {3} والَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْكَ وَمَا أُنزِلَ مِن قَبْلِكَ وَبِالآخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ {4}
أُوْلَئِكَ عَلَى هُدًى مِّن رَّبِّهِمْ وَأُوْلَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ{5})

“Бисмилляһир-рохмә́нир-рохы́м

1. Әлиф ля́м-ми́м. 2. Зә́ликәль-китә́бү ля́ ройбә фи́һ. Һудәл-лиль-муттәкъы́н. 3. Әллязи́нә ю’мину́нә биль-гъойби үә юкүы́ймү́нәс-соля́тә үә мим-мә́ розәкънә́һүм юнфикъу́н. 4. Үәллязи́нә ю’мину́нә бимә́ уңзиля иляйкя үә мә́ уңзиля миң къобьлик, үә биль-ә́хъироти һүм ю́къыну́н. 5. Үля́-икя ‘аля́ һүдәм-мир-роббиһим үә үля́-икя һүмүль-муфлихун”.

## АЯТЬ ӘЛЬ-КҮРСИЙ

**ءاية الكرسي**

(اللهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لاَ تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلاَ نَوْمٌ
لَّهُ مَا فِي السَّمَوَاتِ وَمَا فِي الأَرْضِ مَن ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلاَّ بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلاَ
يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِّنْ عِلْمِهِ إِلاَّ بِمَا شَاء وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضَ وَلاَ يَؤُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ
الْعَظِيمُ) {255}

## АЯТЬ ӘЛЬ-КҮРСИЙнең транскрипциясе

“Алла́һу ля́ иля́һә илля́ Һүәль-Хаййюль-Къоййю́м,
Ля́ та’хъузүһү́ синәтү-үа ля́ нәү́м,
Ляһу́ мә́ фис-сәмә́үә́ти үә мә́ филь-әрд,

Мәң з̲әлляз̲и́ яшфә‘у ‘ындәһү́ илля́ би-из̲ниһ,
Я‘аляму мә́ бәйнә әйди́һим үә мә́ хъольфәһүм,
Үә ля́ юх̲ыйт̲у́нә бишәй-им-мин ‘ыльмиһи́ илля́ бимә́ шә́-а,
Үәси‘а күрсиййюһүс-сәмә́үә́ти үәль-әрд̲,
Үә ля́ яу́дүһү́ х̲ыфз̳уһүмә́ үә һүәль-‘Алийюль-‘Аз̳ы́м”.

## ӘЛЬ-БАКАРА СҮРӘСЕНЕҢ СОҢГЫ
## 284-286 АЯТЬЛӘРЕ

(لِلَّهِ ما فِي السَّمَوَاتِ وَمَا فِي الأَرْضِ وَإِن تُبْدُواْ مَا فِي أَنفُسِكُمْ أَوْ تُخْفُوهُ يُحَاسِبْكُم بِهِ اللّهُ فَيَغْفِرُ لِمَن يَشَاء وَيُعَذِّبُ مَن يَشَاء وَاللّهُ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ {284}
ءامَنَ الرَّسُولُ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْهِ مِن رَّبِّهِ وَالْمُؤْمِنُونَ كُلٌّ ءامَنَ بِاللّهِ وَمَلآئِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ لاَ نُفَرِّقُ بَيْنَ أَحَدٍ مِّن رُّسُلِهِ وَقَالُواْ سَمِعْنَا وَأَطَعْنَا غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ {285} لاَ يُكَلِّفُ اللّهُ نَفْسًا إِلاَّ وُسْعَهَا لَهَا مَا كَسَبَتْ وَعَلَيْهَا مَا اكْتَسَبَتْ رَبَّنَا لاَ تُؤَاخِذْنَا إِن نَّسِينَا أَوْ أَخْطَأْنَا رَبَّنَا وَلاَ تَحْمِلْ عَلَيْنَا إِصْرًا كَمَا حَمَلْتَهُ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِنَا رَبَّنَا وَلاَ تُحَمِّلْنَا مَا لاَ طَاقَةَ لَنَا بِهِ وَاعْفُ عَنَّا وَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَآ أَنتَ مَوْلاَنَا فَانصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ {286})

Транскрипция

“Лилля́һи ма́ фис-сәмә́үә́ти үә мә́ филь-әрд̲ъ, үә иң түбдү́ мә́ фи́ әңфүсикүм әү түхъфү́һү юх̲ә́сибькүмм-биһилля́һ, фә ягъфиру лимәййяшә́-ү, үәлло́һү ‘аля́ күлли шәй-иң к̲ъоди́рь (284). Әмәнәр-росүлю бимә́ үңзиля иляйһи мир-робиһи́ үәль-мү’минү́н, күллюн ә́мәнә билля́һи үә мәля́-икәтиһи үә күтүбиһи́ үә русүлиһ, ля́ нуфәррик̲ъу бәйнә әх̲әдим-мир-русүлиһ, үә к̲ъо́лю́ сәми‘нә́ үә әт̲о‘нә́ г̲ъуфро́нәкя Роббәнә́ үә иляйкяль-мәс̳ырь (285). Ля́ юкяллифулло́һу нәфсән илля́ вус‘аһә́, ляһә́ мә́ кясәбәт үә ‘аляйһә́ мәктәсәбәт, Роббәнә́ ля́ тү-ә́хъиз̲нә́ ин-нәси́нә́ әү әхът̲о’нә́, Роббәнә́ үә ля́ тәх̲миль ‘аляйнә́ ис̳ърон кямә́ хәмәльтәһу́ ‘аляллязи́нә миң к̲ъобьлинә́, Роббәнә́ үә ля́ түхәммильнә́ мә́ ля́ т̲о́к̲ъотә лянә́ биһ, үә‘афү ‘аннә́ үәг̲ъфирь лянә́ үәрх̲әмнә́, Әңтә мәүля́нә́ фәңс̳ъурнә́ ‘аляль-к̲аумиль-кя́фири́н (286)”.

⊥

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

(يس {1} وَالْقُرْءانِ الْحَكِيمِ {2} إِنَّكَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ {3} عَلَى صِرَاطٍ مُّسْتَقِيمٍ {4} تَنزِيلَ الْعَزِيزِ الرَّحِيمِ {5}
